# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Мокшы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

“13” ноябрь 2023 ел                                                                                № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 13 ноябрендә “Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Мокшы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан, мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрбиләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Мокша авылы территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачларны кисү һәм куаклар, үлән чабу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Мокша авылы урам юлларын ремонтлау һәм каплау (вак таш сатып алу, урам юлларын ремонтлау һәм урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү).

«РИЗА»                                                  «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә **40** (кырык) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны **22** (егерме ике) кеше, бу **55 %** тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“**Әйе**” позициясе өчен халык җыенында катнашучы **22** (егерме ике) кеше тавыш бирде;

“**Юк**” позициясе өчен җыенда катнашучыларның **0** (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Мокшы авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Мокшы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк

гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан, мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрбиләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Мокша авылы территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачларны кисү һәм куаклар, үлән чабу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Мокша авылы урам юлларын ремонтлау һәм каплау (вак таш сатып алу, урам юлларын ремонтлау һәм урнаштыру буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү) – мәсьәләсен кабул итәргә.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Мокшы авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Мокшы авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Өҗем авыл җирлеге башлыгы Вәлиев А.Т.